ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗИРЕКЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ
НОВОШЕШМИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Ленина, д. 53,
с. Ерыклы, 423185

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯҢА ЧИШМӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЗИРЕКЛЕ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Ленин урамы, 53,
Зирекле авылы, 423185

тел., факс: (8-4348) 38-6-76, zarek.nsm@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ | КАРАР

2023 елның 10 февраленнән | № 5

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Зирекле авыл җирлеге башкарма комитетының 2021 елның 28 октябрендәге 14 номерлы «Нотариаль гамәлләр кылу буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Нотариат турында Россия Федерациясе законнары нигезләре» 1993 елның 11 февралендәге 4462-1 номерлы Россия Федерациясе Законының 37 статьясы, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль закон, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 14 июлендәге 339-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Зирекле авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Зирекле авыл җирлеге башкарма комитетының 28.10.2021 ел 14 нче номерлы «Нотариаль гамәлләр кылу буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» карарына киләсе үзгәрешләр кертергә:

1.5 пунктына түбәндәге эчтәлектәге 13 пунктча өстәргә:

«13) нотариаль расланган килешүләрнең эчтәлеген чагылдыручы документларның дубликатларын бирү.».

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru, Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга: http://novosheshminsk.tatarstan.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үзем остемдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Зирекле авыл җирлеге башлыгы | Ж.Г. Гайфетдинов